КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 март г.Казань № 224

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче; 2020 ел, 14 июль, 590 нчы; 2020 ел, 5 август, 656 нчы; 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче; 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның $3.3^{20}$ пунктчасында «Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә карата дәүләт контроле» сүзләрен «Россия Федерациясе Музей фонды торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

$3.3^{23}$ пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктта «Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә карата дәүләт контроле» сүзләрен «Россия Федерациясе Музей фонды торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин